**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«4» сентябрь, 2019 ел Яр Чаллы № 3753

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында шәхси мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау турында

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 21 мартындагы 211 санлы карары белән расланган «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган бурычларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлегендәге 1 пункт «б» пунктчасы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында шәхси мәгълүматларны эшкәртү һәм саклау турында нигезләмәне 1 кушымта ннигезендә;

1.2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында шәхси мәгълүматларны иясезләндерү буенча чаралар үткәрүгә җаваплы вазыйфалар исемлеген 2 кушымта нигезендә;

1.3. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәренең типлаштырылган йөкләмә формасын (аның белән хезмәт килешүе өзелгән очракта, вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктатырга кирәк) 3 кушымта нигезендә;

1.4. Шәхси мәгълүматларны тапшырудан баш тартуның юридик нәтиҗәләрен шәхси мәгълүматлар субъектына аңлатуның типлаштырылган формасын 4 кушымта нигезендә;

1.5. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында шәхси мәгълүматларны эшкәртүне яки шәхси мәгълүматларга үтемлелекне тәэмин итүне күздә тоткан вазыйфалар исемлеген 5 кушымта нигезендә;

1.6. Шәхси мәгълүматлар эшкәртелә торган биналарга керү тәртибен 6 кушымта нигезендә;

1.7. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәренең, башка шәхси мәгълүматлар субъектларының шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә типлаштырылган килешү формасын 7 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов